**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения

В связи с выявлением заболевания высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения, в соответствии со статьей $3^1$, 17 Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии», приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 27 марта 2006 года № 90 **постановляю**:

1. Установить ограничительные мероприятия (карантин) по высокопатогенному гриппу птиц на период до их отмены на следующих отдельных территориях Республики Татарстан:

частное подворье дома № 34-А по улице Школьная в поселке железнодорожной станции Каратун Апастовского района;

частное подворье дома № 28 по улице Пушкина в деревне Малые Кокузы Апастовского района;

частное подворье дома № 11 по улице Фрунзе в селе Шланга Дрожжановского района;

частное подворье дома № 2 по улице Заречная в селе Ульянково Кайбицкого района;

частное подворье дома № 3 по улице Вахитова в поселке городского типа Камское Устье Камско-Устьинского района;

частное подворье дома № 16 по улице Профсоюзная в поселке городского типа Камское Устье Камско-Устьинского района;

частное подворье дома № 5 по улице Баки Урманче в поселке городского типа Камское Устье Камско-Устьинского района;

частное подворье дома № 11 по улице Гафури в деревне Вожжи Тетюшского района.

2. Утвердить прилагаемый Перечень ограничений на оборот птицы, продуктов птицеводства, кормов и кормовых добавок на отдельных территориях Республики Татарстан, определенных пунктом 1 настоящего Указа, на период до их отмены.

3. Определить:

а) эпизоотические очаги в пределах следующих отдельных территорий Республики Татарстан (далее – неблагополучные пункты):

частное подворье дома № 34-А по улице Школьная в поселке железнодорожной станции Каратун Апастовского района;

частное подворье дома № 28 по улице Пушкина в деревне Малые Кокузы Апастовского района;

частное подворье дома № 11 по улице Фрунзе в селе Шланга Дрожжановского района;

частное подворье дома № 2 по улице Заречная в селе Ульянково Кайбицкого района;

частное подворье дома № 3 по улице Вахитова в поселке городского типа Камское Устье Камско-Устьинского района;

частное подворье дома № 16 по улице Профсоюзная в поселке городского типа Камское Устье Камско-Устьинского района;

частное подворье дома № 5 по улице Баки Урманче в поселке городского типа Камское Устье Камско-Устьинского района;

частное подворье дома № 11 по улице Гафури в деревне Вожжи Тетюшского района;

б) угрожаемые зоны в пределах территорий радиусом 5 км от границ неблагополучных пунктов, включая следующие отдельные территории Республики Татарстан:

поселок железнодорожной станции Каратун, село Бишево, поселок Свияжский, село Булым-Булыхчи, село Эбалаково, село Мурзино, село Давликеево Апастовского района;

деревня Малые Кокузы, село Кабы Копри, село Большие Кокузы, село Ясашно-Барышево Апастовского района;

село Шланга, село Матаки, село Мочалей, село Чувашские Ишли Дрожжановского района;

село Ульянково, село Старые Чечкабы, деревня Корноухово, поселок Воскресенский, деревня Победа Кайбицкого района;

поселок городского типа Камское Устье Камско-Устьинского района;

деревня Вожжи, село Сюндюково, село Татарская Беденьга Тетюшского района, село Альшеево, село Старые Мертли, деревня Яскуль Буинского района;

в) зоны наблюдения в пределах территорий радиусом 10 км от границ неблагополучных пунктов, включая следующие отдельные территории Республики Татарстан:

поселок городского типа Апастово, село Старое Бурнашево, село Деушево, село Нижний Биябаш, село Средний Биябаш, деревня Сибирчи, село Среднее Балтаево, деревня Нижнее Балтаево, деревня Чиреево, село Починок-Енаево, деревня Табар-Черки, деревня Старые Енали, деревня Курмашево, село Верхний Индырчи, село Шамбулыхчи Апастовского района;

деревня Азимово, село Альмендерово, село Шонгуты, деревня Утямишево, деревня Семь Ключей, село Шигаево, деревня Берляш Апастовского района, деревня Заборная Поляна, село Большие Меми, деревня Нижнее Озеро, деревня Канаш Верхнеуслонского района, село Старое Барышево, деревня Картапа Камско-Устьинского района;

деревня Татарские Тюки, село Старые Какерли, село Старые Ишли Дрожжановского района;

село Большие Кайбицы, село Малые Кайбицы, деревня Афанасьевка, село Берлибаш, деревня Мурза Берлибаш, деревня Плетени, село Большое Подберезье, село Малое Подберезье, деревня Салтыганово, село Багаево, деревня Кичкеево, деревня Муратово, село Надеждино Кайбицкого района;

поселок городского типа Куйбышевский Затон, поселок городского типа Тенишево, село Уразлино, деревня Малые Кармалы, деревня Салтыганово, село Большие Кармалы, деревня Малое Мереткозино Камско-Устьинского района;

село Бакрчи, поселок Татарское Черепаново, деревня Чувашское Черепаново, деревня Чувашский Чикилдым, деревня Татарский Чикилдым, село Бессоново, село Утямишево Тетюшского района, село Бюрганы, село Кошки-Шемякино, деревня Раково, село Старые Бурундуки, деревня Чувашский Сарыкамыш, деревня Канава Буинского района, поселок железнодорожной станции Бурундуки Дрожжановского района.

4. Главному управлению ветеринарии Кабинета Министров Республики Татарстан разработать и утвердить планы мероприятий по ликвидации очагов высокопатогенного гриппа птиц и предотвращению распространения возбудителя болезни на территории Республики Татарстан.

5. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Кабинет Министров Республики Татарстан.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань, Кремль
21 июля 2018 года
№ УП-518

Утвержден
Указом Президента
Республики Татарстан

от «21» июля 2018 года

№ УП-518

**Перечень**
**ограничений на оборот птицы, продуктов птицеводства, кормов и кормовых добавок на отдельных территориях Республики Татарстан**

На период действия ограничительных мероприятий (карантина) на территориях неблагополучных пунктов:

закрыть доступ на территорию посторонним лицам и транспорту;

не допускать посещения неблагополучных пунктов посторонними лицами, кроме персонала, непосредственно их обслуживающего, и дополнительно закрепленных на период проведения мероприятий работников и специалистов в области ветеринарии;

ограничить передвижение персонала, обслуживающего неблагополучную группу птиц, по территории, исключить его контакт с другими птицами и ухаживающими за ними лицами;

организовать бескровный убой больной птицы, сбор павшей и убитой птицы в герметичную тару;

провести при массовом бескровном убое больной птицы ее захоронение в установленном порядке в условиях, исключающих рассеивание предполагаемого возбудителя болезни во внешней среде;

прекратить перемещение птицы внутри эпизоотического очага и вывоз из него птицы, яиц и других продуктов птицеводства, а также вывоз кормов, инвентаря, оборудования, помета;

прекратить посещение других домовладений, где имеется домашняя птица, вывоз живой птицы и полученной от нее продукции, вынос (вывоз) инвентаря, оборудования, помета;

прекратить выгул или иное использование птицы за границами эпизоотического очага;

приостановить торговлю птицей;

закрыть дороги (тропы), ведущие из неблагополучного пункта, выставить необходимое количество круглосуточных контрольно-пропускных постов, оборудованных дезбарьерами, пароформалиновыми камерами для обработки одежды и дезинфекционными установками, с круглосуточным дежурством, с привлечением ветеринарных инспекторов и сотрудников правоохранительных органов;

ограничить передвижение транспорта в зоне карантина, при этом допущенный в карантинную зону транспорт подлежит обязательной дезинфекции на въезде и выезде из нее;

провести мероприятия по убою и уничтожению восприимчивого поголовья.

___________

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында**

Йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү очрагы ачыклану һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2006 елның 27 мартындагы 90 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы барлыкка килүгә бәйле рәвештә, аларны бетерү турында карар кабул ителгәнгә кадәр, чикләү чараларын (карантин) кертергә:

Апас районы Каратун тимер юл станциясе поселогының Мәктәп урамындагы 34-А номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Апас районы Кече Күккүз авылының Пушкин урамындагы 28 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Чүпрәле районы Шланга авылының Фрунзе урамындагы 11 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Кайбыч районы Ульянково авылының Елга аръягы урамындагы 2 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Кама Тамагы районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогының Вахитов урамындагы 3 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Кама Тамагы районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогының Профсоюз урамындагы 16 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Кама Тамагы районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогының Бакый Урманче урамындагы 5 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Тәтеш районы Башчы авылының Гафури урамындагы 11 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы.

2. Әлеге Указның 1 пункты нигезендә билгеләнгән Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә кош, кошчылык продуктларын, азык һәм азыкка өстәмәләрнең әйләнешенә чикләүләрнең кушымтада

бирелүче исемлеген, аларны бетерү турында карар кабул ителгәнгә кадәр, расларга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:
а) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләре (алга таба – имин булмаган пунктлар) чикләрендә эпизоотия чыганагын;
Апас районы Каратун тимер юл станциясе поселогының Мәктәп урамындагы 34-А номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;
Апас районы Кече Күккүз авылының Пушкин урамындагы 28 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;
Чүпрәле районы Шланга авылының Фрунзе урамындагы 11 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;
Кайбыч районы Ульянково авылының Елга аръягы урамындагы 2 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;
Кама Тамагы районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогының Вахитов урамындагы 3 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;
Кама Тамагы районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогының Профсоюз урамындагы 16 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;
Кама Тамагы районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогының Бакый Урманче урамындагы 5 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;
Тәтеш районы Башчы авылының Гафури урамындагы 11 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;
б) имин булмаган пунктлар чикләреннән 5 км радиустагы территория чикләрендә, Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрен кертеп, куркыныч янау зонасын:
Апас районының Каратун тимер юл станциясе поселогы, Биеш авылы, Свияжский поселогы, Болын-Балыкчы авылы, Ябалак авылы, Морзалар авылы, Дәүләки авылы;
Апас районының Кече Күккүз авылы, Кабык Күпер авылы, Зур Күккүз авылы, Ясаклы Барыш авылы;
Чүпрәле районының Шланга авылы, Матак авылы, Мочәли авылы, Чуаш Ишлесе авылы;
Кайбыч районының Ульянково авылы, Иске Чәчкаб авылы, Корноухово авылы, Воскресенский поселогы, Лобашки авылы;
Кама Тамагы районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы;
Тәтеш районының Башчы авылы, Сөендек авылы, Татар Бидәңгесе авылы, Буа районының Әлши авылы, Иске Мәртле авылы, Яскүл авылы;
в) имин булмаган пунктлар чикләреннән 10 км радиустагы территория чикләрендә, Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрен кертеп, күзәтү зонасын:
Апас районының Апас шәһәр тибындагы поселогы, Кара Борнаш авылы, Дәвеш авылы, Түбән Биябаш авылы, Урта Биябаш авылы, Себерче авылы, Урта Балтай авылы, Түбән Балтай авылы, Чирү авылы, Пүчинкә-Енай

авылы, Табар Черкене авылы, Иске Йомралы авылы, Кормаш авылы, Югары Ындырчы авылы, Шәмбалыкчы авылы;

Апас районының Әҗем авылы, Әлмәндәр авылы, Шонгат авылы, Үтәмеш авылы, Җиде Кизләү авылы, Шыгай авылы, Берләш авылы, Югары Ослан районының Заборная Поляна авылы, Олы Мәми авылы, Нижнее Озеро авылы, Канаш авылы, Кама Тамагы районының Иске Барыш авылы, Кыртапа авылы;

Чүпрәле районының Татар Төкесе авылы, Иске Кәкерле авылы, Иске Ишле авылы;

Кайбыч районының Олы Кайбыч авылы, Кече Кайбыч авылы, Афанасьевка авылы, Бәрлебашы авылы, Морза Бәрлебашы авылы, Плетени авылы, Олы Подберезье авылы, Кече Подберезье авылы, Салтыган авылы, Багай авылы, Кичкеево авылы, Морат авылы, Надеждино авылы;

Кама Тамагы районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы, Тенеш шәһәр тибындагы поселогы, Уразлы авылы, Кече Карамалы авылы, Сатлыган авылы, Олы Карамалы авылы, Кече Мәрәтхуҗа авылы;

Тәтеш районының Бакырчы авылы, Татар Чурапаны авылы, Чуаш Чурапаны авылы, Чуаш Чагылдымы авылы, Татар Чагылдымы авылы, Бессоново авылы, Үтәмеш авылы, Буа районының Боерган авылы, Шәмәк авылы, Раково авылы, Иске Борындык авылы, Чуаш Сарыкамышы авылы, Канава авылы, Чүпрәле районының Борындык тимер юл станциясе поселогы.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы чыганагын бетерү һәм авыру чыганагының Татарстан Республикасы территориясендә таралуын булдырмау буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 21 июль
№ ПУ-518

Татарстан Республикасы
Президентының
2018 елның «21» июлендәге
ПУ-518 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә кош, кошчылык продуктлары, азык һәм азыкка өстәмәләр әйләнешенә чикләүләр исемлеге**

Чикләү чаралары (карантин) гамәле вакытында имин булмаган пунктлар территорияләрендә:

территориягә чит кешеләр керүне һәм транспорт керүне туктатырга;

турыдан-туры хезмәт күрсәтүче персоналдан һәм чаралар уздырыла торган вакытка өстәмә рәвештә объектка беркетелгән ветеринария өлкәсендәге хезмәткәрләр һәм белгечләрдән тыш, имин булмаган пунктларга чит кешеләр керүне тыярга;

кошларның имин булмаган төркеменә хезмәт күрсәтүче персоналның оешма территориясе буйлап йөрүен чикләргә, аларның башка кошлар һәм аларга хезмәт күрсәтүче затлар белән аралашуын булдырмаска;

чир йоктырган кошларны кан чыгармыйча юк итүне, үлгән һәм юк ителгән кошларны герметик тарага җыюны оештырырга;

кан чыгармыйча массачыл төстә кошларны юк итү вакытында, авыру тудыручы дип күздә тотылган чыганакның әйләнә-тирә мохиттә таралуын булдырмау шартларында, үләксәләрне күмүне билгеләнгән тәртиптә уздырырга;

эпизоотия чыганагында булган кошларны күчерүне һәм аннан кошларны, йомыркаларны һәм башка кошчылык продуктларын, шулай ук кош азыгы, эш коралларын, җиһазларны, кош тизәген чыгаруны туктатырга;

йорт кошлары булган башка хуҗалыкларга керүне, кошларны һәм кошчылык продуктларын, эш коралларын, җиһазларны, кош тизәген чыгаруны туктатырга;

объект чикләреннән кошларны чыгаруны һәм аларны башкача файдалануны туктатырга;

кошлар сатуны вакытлыча туктатырга;

имин булмаган пунктлардан чыгу юлларын (сукмакларны) ябарга, кирәкле санда дезинфекцияләү киртәләре, кием-салымны эшкәртү өчен пароформалин камералары һәм дезинфекцияләү җайланмалары белән җиһазландырылган тәүлек әйләнәсе кизү торачак контроль-үткәрү постлары куярга, аларда эшләргә ветеринария инспекторларын һәм хокук саклау органнары хезмәткәрләрен җәлеп итәргә;

карантин зонасында транспорт хәрәкәтен чикләргә, шул исәптән керү рөхсәт ителгән транспорт карантин зонасына кергәндә һәм аннан чыкканда мәҗбүри дезинфекцияләнергә тиеш;

авыруларга аеруча бирешүчән баш санын сую һәм юкка чыгару буенча чаралар уздырырга.